**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**БОГДАШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**БОГДАШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **БОЕРЫК**

23.04.2019 № 8

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль
районы Богдашкино авыл җирлегендә җирләү
буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге
нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр
кыйммәтен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында "2019 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 1 февраленнән Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 5946,47 сум күләмендә 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карар 2019 елның 12 мартыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.
3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлеге территориясендә мәгълүмат стендларында, шул исәптән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында да игълан итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Богдашкино авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Л. Михайлова

Нурлат муниципаль районы
Богдашкино авыл җирлеге Башкарма комитетының
2019 елның 23 апрелендәге 8 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында 2019 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 124,81 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 2103,20 |
| 3. Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 901,44 |
| 4. Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 2817,02 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге Башкарма комитетының
2019 елның 23 апрелендәге 8 номерлы
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында 2018 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 124,81 |
| 2. Мәетне кәфенләү (киендерү-төрү) | 338, 04 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 1675,00 |
| 4. Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 991,60 |
| 5. Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 2817,02 |
| **БАРЛЫГЫ** | **5946,47** |